| 28 | Употребление синонимов и антонимов в речи.<br><br>Синонимнар һәт антонимнарны сөйләмдә куллану. | 1 | 15.11 | | |
| 29 | Омонимы.Аваздаш сүзләр. | 1 | 18.11 | | |
| 30 | Омонимы.Аваздаш сүзләр. | 1 | 20.11 | | |
| 31 | Омонимы.<br><br>Язылышы белән генә аерыла торган омоним сүзләр. | 1 | 22.11 | | |
| 32 | Развитие речи.Обучающее изложение<br><br>Текст белән эш. Өйрәтү характерындагы изложение язу. | 1 | 25.11 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 33 | Работа над ошибками.<br><br>Изложениеда киткән хаталарны анализлау. | 1 | 27.11 | | |
| 34 | Однозначные и многозначные слова.<br><br>Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. | 1 | 29.11 | | |
| 35 | Однозначные и многозначные слова.<br><br>Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. | 1 | 2.12 | | |
| 36 | Выборочный диктант.Сайланма диктант. | 1 | 4.12 | | |
| 37 | Работа над картиной.<br><br>Картина белән эш. | 1 | 6.12 | | |
| 38 | Прямое и переносное значение слов.<br><br>Туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләр.<br><br>*День Героев Отечества (9 декабря)* | 1 | 9.12 | | |
| 39 | Прямое и переносное значение слов.<br><br>Туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләр.<br><br>*Международный день прав человека ( 10 декабря)* | 1 | 11.12 | | |
| 40 | **Контрольное списывание.**<br><br>**Контроль күчереп язу.** | 1 | 12.12 | | |
| 41 | Развитие речи.Обучающее изложение Өйрәтү характерындагы изложение язу. | 1 | 16.12 | | |
| 42 | Повторение.<br><br>Кабатлау. | 1 | 18.12 | | |
| 43 | **Контрольный диктант.**<br><br>**Контроль диктант.** | 1 | 20.12 | | |
| | **Состав слова.**<br><br>**Сүз төзелеше** | **13** | | | |
| 44 | Состав слова.<br><br>Сүз төзелеше. | 1 | 23.12 | | |
| 45 | Состав слова.<br><br>Сүз төзелеше. | 1 | 25.12 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 46 | Окончание.Суффикс.<br><br>Кушымча. Кушымчаларның төрләре (сүз ясагыч һәм сүз төрләндергеч кушымчалар). | 1 | 27.12 | | |
| 47 | Однокоренные слова.<br><br>Тамырдаш сүзләр. | 1 | 10.01 | | |
| 48 | Однокоренные слова.<br><br>Тамырдаш сүзләр. | 1 | 13.01 | | |
| 49 | Окончание.Суффикс.<br><br>Кушымчаларның төрләре. Кушымча. Кушымчаларның төрләре | 1 | 15.01 | | |
| 50 | Суффикс.<br><br>Сүз ясагыч кушымчалар.<br><br>*День детских изобретений (17 января)* | 1 | 17.01 | | |
| 51 | Суффикс.<br><br>Сүз ясагыч кушымчалар. | 1 | 20.01 | | |
| 52 | Окончание.<br><br>Сүзнең лексик мәгънәсен һәм формасын үзгәртә торган кушымчалар.<br><br>*Всемирный день снега (23 января).* | 1 | 22.01 | | |
| 53 | Повторение.<br><br>Кабатлау | 1 | 24.01 | | |
| 54 | Сложные слова.<br><br>Кушма сүзләр. | 1 | 27.01 | | |
| 55 | Сложные слова.<br><br>Парлы сүзләр. | 1 | 29.01 | | |
| 56 | Заимствованные слова.<br><br>Алынма сүзләр. | 1 | 31.01 | | |
| | **Части речи**<br><br>**Сүз төркемнәре** | **28** | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 57 | Имена существительные.Изменение имен существительных по падежам.<br><br>Исем. Исемнәрнең килеш белән төрләнүе. | 1 | 3.02 | | |
| 58 | Изменение имен существительных по падежам.<br><br>Исемнәрнең килеш белән төрләнүе. | 1 | 5.02 | | |
| 59 | **Контрольный диктант.Контроль диктант.** | 1 | 7.02 | | |
| 60 | Работа над ошибками<br><br>Собственные и нарицательные имена существительные<br><br>Хаталар өстендә эш. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Ялгызлык исемнәрдә баш хәреф. | 1 | 10.02 | | |
| 61 | Одушевленные и неодушевленные имена существительные<br><br>Җанлы һәм җансыз предметлар. | 1 | 12.02 | | |
| 62 | Развитие речи.Обучающее изложение Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Өйрәтү характерындагы изложение язу | 1 | 14.02 | | |
| 63 | **Контрольное списывание.**<br><br>**Контроль күчереп язу.**<br><br>*Международный День спонтанного проявления доброты (17 февраля)* | 1 | 17.02 | | |
| 64 | Местоимение.Роль местоимений в предложении<br><br>Зат алмашлыклары. Зат алмашлыкларының җөмләдәге роле | 1 | 19.02 | | |
| 65 | Местоимение.Роль местоимений в предложении<br><br>Зат алмашлыклары. Зат алмашлыкларының җөмләдәге роле. | 1 | 21.02 | | |
| 66 | Множественные и единственные формы местоимений.<br><br>Зат алмашлыклары. Зат алмашлыкларының берлек һәм күплек формалары. | 1 | 24.02 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 67 | Изменение местоимений  по падежам.<br><br>Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнүе. | 1 | 26.02 | | |
| 68 | Творческий диктант.Иҗади диктант. | 1 | 28.02 | | |
| 69 | Изменение глаголов по лицам и числам в единственном числе.<br><br>Фигыль. Фигыльнең берлек санда зат-сан белән төрләнүе<br><br>*Всемирный день чтения вслух (2 марта)* | 1 | 2.03 | | |
| 70 | Изменение глаголов по лицам и числам в единственном числе.<br><br>Фигыльнең берлек санда зат-сан белән төрләнүе. | 1 | 4.03 | | |
| 71 | **Контрольное списывание.**<br><br>**Контроль күчереп язу.** | 1 | 6.03 | | |
| 72 | Вводные слова.<br><br>Кереш сүзләр. | 1 | 9.03 | | |
| 73 | Изменение глаголов по лицам и числам во множественном числе.<br><br>Фигыльнең күплек санда зат-сан белән төрләнүе. | 1 | 11.03 | | |
| 74 | Изменение глаголов по лицам и числам во множественном числе.<br><br>Фигыльнең күплек санда зат-сан белән төрләнүе. | 1 | 13.03 | | |
| 75 | Употребление глаголов 3-го лица единственного числа с существительными во множественном числе.<br><br>3 зат берлек сандагы фигыльләрнең күплек сандагы исемнәр белән кулланылуы.<br><br>*День воссоединения Крыма с Россией (18 марта)* | 1 | 16.03 | | |
| 76 | **Контрольный диктант.**<br><br>**Контроль диктант.** | | 18.03 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 77 | Работа над ошибками.Повторение.<br><br>Хаталар өстендә эшләү. Кабатлау.<br><br>*Всемирный день поэзии (21 марта)* | | 20.03 | | |
| 78 | Употребление глаголов 3-го лица единственного числа с существительными во множественном числе.<br><br>3 зат берлек сандагы фигыльләрнең күплек сандагы исемнәр белән кулланылуы. | 1 | 1.04 | | |
| 79 | Имена прилагательное .<br><br>Сыйфат сүз төркеме. | 1 | 3.04 | | |
| 80 | Имена прилагательное.<br><br>Сыйфат сүз төркеме. | 1 | 6.04 | | |
| 81 | Степени имен прилагательных. Положительная степень прилагательных.<br><br>Сыйфат дәрәҗәләре.Төп дәрәҗә. | 1 | 8.04 | | |
| 82 | Сравнительная степень прилагательных Сыйфатларның чагыштыру дәрәҗәсе. | 1 | 10.04 | | |
| 83 | Развитие речи.Обучающее изложение Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Өйрәтү характерындагы изложение язу. | 1 | 13.04 | | |
| 84 | Работа с текстом .<br><br>Текст белән эш.. | 1 | 15.04 | | |
| | **Предложение.**<br><br>**Җөмлә** | **12** | | | |
| 85 | Предложение . Җөмлә. | 1 | 17.04 | | |
| 86 | Главные члены предложения.<br><br>Җөмләнең баш кисәкләре. | 1 | 20.04 | | |
| 87 | Главные члены предложения.Җөмләнең баш кисәкләре. | 1 | 22.04 | | |
| 88 | Роль сказуемого в предложении.<br><br>Татар телендә хәбәрнең җөмләдәге урыны. | 1 | 24.04 | | |
| 89 | Работа с картиной. Сочинение | 1 | 27.04 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Картина белән эш.Сочинение | | | | |
| 90 | Состав предложения.<br><br>Җөмлә төзелеше. | 1 | 29.04 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 91 | Состав предложения.<br><br>Җөмлә төзелеше. | 1 | 1.05 | | |
| 92 | Состав предложения.<br><br>Җөмлә төзелеше.<br><br>*Международный день борьбы за права инвалидов (5 мая)* | 1 | 4.05 | | |
| 93 | Развитие речи.Обучающее изложение Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Өйрәтү характерындагы изложение язу | 1 | 6.05 | | |
| 94 | Однородные подлежащее.<br><br>Тиңдәш ияләр.<br><br>*День Победы советского народа в Великой Отечественной войне 1941-1945 годов* | 1 | 8.05 | | |
| 95 | Однородные подлежащее.<br><br>Тиңдәш ияләр. | 1 | 11.05 | | |
| 96 | **Промежуточная аттестация. Контрольный диктант.**<br><br>**Арадаш аттестация.**<br><br>**Контроль диктант.** | 1 | 13.05 | | |
| 97 | Повторение. Работа над ошибками<br><br>Хаталар өстендә эшләү. Кабатлау. | 1 | 15.05 | | |
| | **Повторение.**<br><br>**Кабатлау.** | **5** | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 98 | Повторение.Кабатлау. | 1 | 18.05 | | |
| 99 | Повторение.Кабатлау. | 1 | 20.05 | | |
| 100 | Повторение.<br><br>Гомуми кабатлау | 1 | 22.05 | | |
| 101 | Повторение.<br><br>Гомуми кабатлау | 1 | 25.05 | | Уплотнение учебного материала |
| 102 | Повторение.<br><br>Гомуми кабатлау | 1 | | | |

Укыту-методик комплекты:

Туган тел (татар теле). 3 сыйныф. Ике кисәктә. 1 нче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов; [рәссамы Андрей Шляпкин]. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2020. – 104 б.

6. Туган тел (татар теле). 3 сыйныф. Ике кисәктә. 2 нче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов; [рәссамы Андрей Шляпкин]. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2020. – 112 б.

Өстәмә әдәбият

1. Татар теленнән иҗади сочинениеләр һәм изложениеләр. М. Ж .Ахиярова .Казан 2009
2. 1-4 сыйныфлар өчен диктантлар. Я Х Абдрахимова Казан 2009

**Кушымта**

**Укучыларның белемнәрен бәяләүнең критерийлары**

3 сыйныфта эш болай бәяләнә:
“5”- хаталар, төзәтүләр юк;
“4” – 2 орфографик, 1 пунктацион хата яисә 1 орфографик, 2 пунктацион хата;
“3” – 3 - 4 орфографик хата (3 орфографик, 2 пунктацион яисә 5 орфографик, 1 пунктацион хата бар;
“2” – 6-7 орфографик хата бар.

Диктантта хата итеп исәпләнә: сүзне язганда, орфография кагыйдәсен сакламау, сүздәге хәрефләрне төшереп калдыру, бозып язу, сүзләрне алмаштыру, тыныш билгеләре булмау (программа таләпләренә бәйле рәвештә).

Диктантта хата итеп исәпләнми: кагыйдәсе өйрәнелмәгән сүзләрдәге хата, яңа җөмлә баш хәрефтән башланып та, алдагы җөмлә азагында нокта булмау, мәгънәгә зыян китермичә, 1 сүзне башка сүз белән алмаштыру.

Диктантта 1 хата булып исәпләнә: 2 хатаны төзәтү, бер типтагы 2 пунктацион хата, бер үк сүздә кабатланган хата.

Тупас хата булып исәпләнми: сүздә 1 хәрефне 2 тапкыр язу, сүзне юлдан юлга күчергәндә, юл азагында сүзнең башлангыч өлеше язылып, икенче өлешен төшереп калдыру, җөмләдә сүзне ике тапкыр язу.

*Контроль күчереп язуны бәяләү*

| Билге | Хаталар саны |
|---|---|
| | 3 сыйныф |

| | |
|---|---|
| “5” | Хатасы юк. Язуга караганда 1 төгәлсезлек булуы мөмкин. |
| “4” | 1-2 хата, 1 төзәтү. |
| “3” | 3 хата, 1 төзәтү. |
| “2” | 4 хата, 1-2 төзәтү. |

*Грамматик биремнәр болай бәяләнә:*
“5” – биремнәр хатасыз үтәлгән, кагыйдәләр һәм билгеләмәләр аңлы үзләштерелгән, мөстәкыйль кулланылган;
“4” - кагыйдәләр һәм билгеләмәләр аңлы үзләштерелгән, биремнәрне үтәгәндә, белеп кулланылган;
“3” – билгеле күләмдә өйрәнелгән материал үзләштерелгән, биремнәрнең яртысыннан азрагы дөрес үтәлгән.
“2” – материал начар үзләштерелгән, грамматик биремнәрнең күпчелеге үтәлмәгән.
*Сүзлек диктантлары(8 – 10 сүз)*
Бәяләү нормалары:
“5” – хатасыз эш;“4” – 1 хата, 1 төзәтү;“3” – 2 хата, 1 төзәтү;“2” – 3-4 хата.

**Контроль – бәяләү материалы**

1. **Кереш контроль диктант.**

**Максат:** Грамоталы язу күнекмәсен тикшерү.

**Дару үләне.**

Сәхипкамал әби икенче көнне Тәнзиләне елга буена алып төште. Яр буендагы дымлы урыннарны эт тигәнәге үләне каплап алган иде. Чәчәкләргә бөреләнгән генә вакытлары. Аларның очларын нәкъ шундый чакта җыярга кирәк.

Дымлы урыннарда песи үләне дә шактый күп иде. Әмма Сәхипкамал әби аларга кагылмады. Аның орлыклары өлгергәч, тамырларын көз көне казып алалар. Йөрәк авыртканда эчә торган валерьянка тамчыларын шулардан ясыйлар инде.

Грамматик биремнәр:

1 нче бирем. Сүзләрне иҗекләргә бүл.

1 нче варинат – 1 нче җөмләдә;

2 нче варинат – 2 нче җөмләдә.

2 нче бирем. Түбәндәге биремнәр буенча тексттан сүзләр күчереп яз.

1 нче варинат – 5 авазлы, 5 хәрефле.

2 нче варинат – 6 авазлы, калын әйтелешле.

3 нче бирем. Сүзгә аваз-хәреф анализы яса.

## 2. Контроль диктант “Лексика. Сүз. Сүз төзелеше”

**Максат:** “Лексика. Сүз. Сүз төзелеше” темасы буенча белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Туган көн.

Бүген Фәридәнең туган көне. Әнисе, иртүк торып, бик матур торт пешерде. Өстәлгә тәмле-татлы сый-хөрмәт тезелде.

Өстендәге күлмәге дә бик матур бүген Фәридәнең. Анысын да әнисе тегеп кидерде аңа. Чәчләренә күлмәге төсле үк тасмадан күбәләкләр такты.

Өйләре дә искиткеч матур бүген аларның. Бөтен нәрсә ялт иткән! Бар да чиста, бар да пөхтә, бар да матур, күңелле.

Грамматтик биремнәр:

1 нче бирем.

Тексттан күчерелмә мәгънәдәге сүзне табып, астына сыз.

2 нче бирем.

Тексттан синоним сүзләрне күчереп яз.

3 нче бирем.

Сүзтезмә белән белдерелгән лексик берәмлекләрне гади карандаш белән әйләндереп ал.

## 3. Контроль диктант “Сыйфат”

Максат: Сыйфат турында белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Батыр танкист.

Өлкән сержант Рәхим Җиһаншин моңарчы бу илне картадан гына белә иде. Хәзер ул шушы илдә.

Түгәрәк йөзле, кара күзле, чем-кара кашлы бу таза егет Бөек Ватан сугышы башланган көннәрдә армия сафында иде. Ул ак финнарга каршы сугышта да катнашты.

Салкын карлы – буранлы көннәрдә бозлы кыялар һәм калын урманнар, сазлыклар һәм күлләр аша дошманны куа-куа, һәрвакыт алга бардылар. (54 сүз)

Грамматик биремнәр:

1 нче бирем: бирелгән сыйфатларны дүрт дәрәҗәгә куеп яз.

1 нче вариант: кара, салкын.

2нче вариант: түгәрәк, таза

2нче бирем: әйтелгән абзацларда сыйфатларны үзләре ачыклап килгән исемнәр белән парлап яз.

1 нче вариант: 2 нче абзац.

2нче вариант: 3 нче абзац.

**4. Контроль күчереп язу. Алмашлык. Текстны исемләү.**

Максат: Алмашлык турында белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Аю белән хатын

Әүвәлге заманда бер хатын урак урырга баласы белән барган, ди. Ул ура башлагач ук аның янына бер Аю килгән. Ул аюның аягына шырпы кадалган икән, ди. Ул хатынга аягын күрсәтергә килгән булган. Хатын аның аягыннан шырпысын алган. Шуның өчен Аю хатынга бер умарта бал китереп биргән, ди.

5.**Контроль диктант.** “Алмашлык” темасын кабатлау

Максат: Алмашлык турында белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Янар тау.

Урал борылышы артыннан өч вулкан – өч янар тау күренә башлады. Алар бик якын тоела. Ләкин ерак икәнен яхшы белә Зөфәр. Аларның ак түбәләре кичке шәфәкъ нурында коена. Иң биегенең очыннан күксел томан күтәрелә. Югарыда ул кып-кызыл төскә манылган. Томан түгел, янар тауның кайнар сулышы бу. (46 сүз)

Грамматик биремнәр.

1 нче бирем.

Алмашлыкларны күчереп яз, янәшәсендә кайсы затка караганын билгелә.

2 нче бирем. Алмашлыкларны үзләре алмаштырып килгән сүзләрне парлап. Яз.

*3 нче бирем.

Җөмләне сорау алмашлыгы кертеп үзгәртеп яз.

**5. Контроль күчереп язу.**

Максат: Хатасыз язу күнекмәсен үстерү, тикшерү.

Матур кошлар.

Чәрелдәвек – матур кош. Ул сыерчык хәтле диярлек. Түше кызгылт – сары, баш түбәсендә артык тырпаеп торган карасу – кызгылт “чәче” үзенә бик килешә. Канатлары кара, сары һәм кызыл төсләр белән бизәлгән.

Карабүреккә юкка гына шундый исем бирмәгәннәр. Ул, чыннан да, башына кара бүрек кигән шикелле тоела. Түше һәм корсак асты кып-кызыл. (47 сүз).

Грамматик биремнәр:

1 нче бирем. Әйтелгән җөмләләрдә хәбәрнең астына сыз, кайсы сүз төркеме белән белдерелгәнен күрсәт.

1 нче вариант – 1 нче җөмләдә.

2нче вариант – соңгы җөмләдә.

2 нче бирем. Текст эчтәлегенә туры килгән җөмләләр уйлап яз.

1 нче вариант – сорау җөмләләр.

2 нче вариант – боеру җөмләләр.

### 7. Контроль диктант. Кисәкчә.

Максат: Кисәкчә турында белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Шулвакыт ертык болыт иренеп кенә кояшны каплады. Вак кына яңгыр сибәли башлады. Авыл капкасы янында ат пошкырган тавыш ишетелде. Бераздан ул үзе дә күренде. Арбада, иске мылтыгын кочаклап, сунарчы Әләү абый утырган иде. Малайлар, кунак кызын да онытып, аңа таба йөгерделәр. Мин генә каккан казык кебек урынымда басып калдым: Әләү абый янәшәсендә кызгылт төлке сузылып ята иде... (57 сүз)

Грамматик биремнәр.

1. Кисәкчәләрнең asларына сызыгыз.
***2.*** Бирелгән кисәкчәләр белән җөмлә төзеп языгыз. 1 рәт: ***да, ук, ич***
1 рәт: ***тә, кына, бит.***

### 8.Контроль күчереп язу “Җөмлә”

Максат: Җөмлә турында белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

**Күңелләрдә мәңге сакланыр.**

Тыныш билгеләрен куеп язарга.

Мәскәү Кремле стенасы буендагы бакчада солдат кабере бар Монда күмелгән батырның исемен берәү дә белми ләкин бу билгесез солдатның үз – үзен аямыйча сугышып үлүен һәркем хәтерли Ул башкалабыз өчен барган сугышларның берсендә һәлак булган

Дошман җиңелде Мәскәүгә үтеп керә алмады

1965 нче елда, Җиңү көнен бәйрәм иткәндә, Мәскәүгә герой – шәһәр исемен бирделәр Башкалабыз өчен барган соңгы сугышларда һәлак булган батырның гәүдәсен казып алдылар да Кремль стенасы буена күмделәр

Менә хәзер шушы кабер өстендә Мәңгелек ут яна (74 сүз)

### 9.Контроль диктант “Җөмләнең баш кисәкләре”

Максат: Җөмләнең баш кисәкләре турында белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Яз җитә.

Табигатьтә яз билгеләре күренде. Еракта каралып торган урман да яшәрде. Көн урталарында урман өстендә зәңгәр нур балкый.

Кыш буе ак мамык шикелле, түбәләрдә күпереп яткан карлар тыгызланды, басылды. Түбә читләрендә карандаш очы кадәрле бозлар күренгли башлады. Чана юллары карала төште. Менә кара каргалар да су буендагы биек тал агачларына оя ясадылар.

Кояш та хәзер җиргә турырак карый. Ул әкренләп табигатьне җанландырды.

Грамматик биремнәр.

1 нче бирем. Әйтелгән җөмләләрдә баш кисәкләрнең асларына сыз.

1 нче вариант – 1,2 нче җөмләдә.

2 нче вариант – 3 нче, соңгы җөмләдә.

2 нче бирем. Тиңдәш хәбәрле җөмләне табыгыз, тиңдәш хәбәрләр астына сызыгыз.

*3 нче бирем. 1 нче абзацтагы җөмләләрне җыйнак җөмләгә әйләндереп яз.

**10.Контроль күчереп язу.**

Максат: Белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен тикшерү.

**Солтания белән күбәләк.**

Көн бик эссе. Солтаниянең бик тә, бик тә тәмле туңдырма ашыйсы килә. Ул әле бик кечкенә, аңа бары дүрт яшь кенә. Кечкенә булса да, урамга берүзе генә чыкты әле менә.

Солтания тирә-якка күз салды, ләкин ул якын-тирәдә туңдырма сатучы күрмәде. Инде кая барырга дип торганда, Солтания һавада бөтерелеп очкан бер матур күбәләкне шәйләп алды. Туңдырма ашыйсы килүен онытып, Солтания әлеге күбәләк артыннан китте. Матур күбәләк аның үз артыннан ияргәнен сизде, ахры, тиз генә юлның теге ягына очты. Солтания янә артыннан иярде...

**Уку елының II яртыеллыгына тест**

Максат: 3 нче сыйныфта өйрәнелгән белем-күнекмәләрнегомумиләштереп, гамәлдә куллана белү күнекмәсен тикшерү.

1. Өйрәнгән сүз төркемнәрен кулланып, түбәндәге биремнәр буенча җөмлә уйлап языгыз. (2 балл)
   1 нче рәт: кошлар турында.
   2 нче рәт: дуслык турында.
2. Сүзләргә икешәр төрләндергеч һәм ясагыч кушымча өстәп күчереп языгыз. (2 балл)
   1 нче рәт: күз, боз.

   2 нче рәт: сүз, кар.

3. Бирем буенча җөмлә уйлап языгыз. ( 1 балл)

   1 нче рәт: кушма сүз кергән.

   2 нче рәт: парлы сүз кергән.

4. Биремнәр буенча өч җөмләдән торган кечкенә текст төзеп языгыз. (3 балл)

   1 нче рәт: *Язгы көн.*

   2 нче рәт: *Язгы урман.*

5. Фигыльләрне юклык формасында кулланып, өч җөмлә уйлап языгыз. (3 балл)

Бәяләү критерийлары:

8 балл – “5”ле

6-7 балл – “4” ле

4-5 балл – “3” ле

4 тән түбән – “2” ле

**Еллык контроль  диктант**

Максат: 3 нче сыйныфта өйрәнелгән белем-күнекмәләрне гомумиләштереп, гамәлдә куллана белү, хатасыз  язу күнекмәсен тикшерү.

Июнь ае – табигатьнең иң матур, иң яшь чагы.

Таң ата. Бабам бакчадагы умарталыкка китте. Мин дә аның артыннан иярдем. Бакчадагы һәр җиләк-җимеш төймәсендә чык тамчысы җемелди. Дөнья уянып килә.

Умарталардагы бал кортлары да кузгалды. Алар тирә-яктагы гөлләр дөньясына таралды. Бу эшчән бөҗәкләр чәчәкләр тирәсендә ыгы-зыгы киләләр. Һәрбер умарта корты, тырыша-тырыша, бал җыя. Бергенә корт та эшсез тормый.

Һавада тәмле ис – бал исе аңкый. (64 сүз)

**Контроль изложение.**

Максат: Ишетеп кабул иткән текстның эчтәлеген бирә белү һәм хатасыз язу күнекмәсен тикшерү.

Аккош.

Урманда бер күл бар. Күл буенда кечкенә йортта каравылчы бабай яши.

Көннәрнең берсендә бабай күлдәге камыш арасында аккош баласы күрә. Ул аны тотып өенә алып кайта да тәрбияләп үстерә. Бабай иртән торып балыкка китә, ә аккош күлдә йөзә, җим ашый.

Бабайның эте Сурка да аккош белән бик тиз дуслашты. Алар бергәләп йөрергә чыктылар. Аккош суда йөзә, ә Сурка яр буйлап бара.

Көз көне көньякка китүче аккошлар күлгә ял итәргә төштеләр. Аккошлар йөриләр, җим ашыйлар, ерак җиргә китәргә көч җыялар. Бабайның аккошы башта алар арасына кермичә, читтә генә йөзеп йөрде. Берничә көннән ул аларга ияләште һәм шул төркем белән көньякка очып китте.

**Кушымта**

**Укучыларның белемнәрен бәяләүнең  критерийлары**

3  сыйныфта эш болай бәяләнә:
“5”- хаталар, төзәтүләр юк;
“4” – 2 орфографик, 1 пунктацион хата яисә 1 орфографик, 2 пунктацион хата;
“3” – 3 - 4 орфографик хата (3 орфографик, 2 пунктацион яисә 5 орфографик, 1 пунктацион хата бар;
“2” – 6-7 орфографик хата бар.

Диктантта хата итеп исәпләнә: сүзне язганда, орфография кагыйдәсен сакламау, сүздәге хәрефләрне төшереп калдыру, бозып язу, сүзләрне алмаштыру, тыныш билгеләре булмау (программа таләпләренә бәйле рәвештә).

Диктантта хата итеп исәпләнми: кагыйдәсе өйрәнелмәгән сүзләрдәге хата, яңа җөмлә баш хәрефтән башланып та, алдагы җөмлә азагында нокта булмау, мәгънәгә зыян китермичә, 1 сүзне башка сүз белән алмаштыру.

Диктантта 1 хата булып исәпләнә: 2 хатаны төзәтү, бер типтагы 2 пунктацион хата, бер үк сүздә кабатланган хата.

Тупас хата булып исәпләнми: сүздә 1 хәрефне 2 тапкыр язу, сүзне юлдан юлга күчергәндә, юл азагында сүзнең башлангыч өлеше язылып, икенче өлешен төшереп калдыру, җөмләдә сүзне ике тапкыр язу.

*Грамматик биремнәр болай бәяләнә:*
"5" – биремнәр хатасыз үтәлгән, кагыйдәләр һәм билгеләмәләр аңлы үзләштерелгән, мөстәкыйль кулланылган;
"4" - кагыйдәләр һәм билгеләмәләр аңлы үзләштерелгән, биремнәрне үтәгәндә, белеп кулланылган;
"3" – билгеле күләмдә өйрәнелгән материал үзләштерелгән, биремнәрнең яртысыннан азрагы дөрес үтәлгән.
"2" – материал начар үзләштерелгән, грамматик биремнәрнең күпчелеге үтәлмәгән.
*Сүзлек диктантлары(8 – 10 сүз)*
Бәяләү нормалары:
"5" – хатасыз эш;"4" – 1 хата, 1 төзәтү;"3" – 2 хата, 1 төзәтү;"2" – 3-4 хата.

**Изложение һәм сочинениене бәяләү**

1. Эчтәлек дөрес һәм эзлекле итеп ачылса, җөмләләр грамматик яктан дөрес төзелсә, хаталар булмаса яки 1 хата җибәрелсә (орфографик, грамматик, пунктуацион, стиль, фактик, логик хаталарның берсе генә булса), "5"ле билгесе куела.
2. Эчтәлек дөрес ачылып та, эзлеклелек сакланмаса, 3 хата (орфографик, грамматик, пунктуацион, стиль, фактик, логик хаталардан бары тик өчесе генә) булса, "4"ле билгесе куела.
3. Текстның төп эчтәлеге нигездә бирелеп тә, эзлеклелек сакланмаса, стиль, логик яктан төгәлсезлекләр булса, 6 хата ((орфографик, грамматик, пунктуацион, стиль, фактик, логик хаталар) җибәрелсә, "3"ле билгесе куела.
4. Эчтәлек дөрес һәм эзлекле ачылмаса, 7-10 хата (орфографик, грамматик, пунктуацион, стиль, фактик, логик хаталар) китсә, "2"ле билгесе куела

Грамматик белемнәрне бәяләү

Ана телендә өйрәнелгән грамматик күренешләрне сөйләмдә дөрес кулланса; тупас булмаган 1-2 хата ж;ибәрсә; укытучыга 1-2 ачыкланучы сорау бирергә туры килсә, "5" ле куела.

Төп таләпләрне үтәп тә, 2 грамматик хата ясаса, ләкин өстәмә сораулар саны 3 тән артмаса, "4" ле куела.

Грамматик форма һәм синтаксис конструкцияләрне сөйләмдә куллана белсә, ләкин 4-5 грамматик хата җибәрсә, "3" ле куела.

Грамматик күнекмәләр начар үзләштерелсә,грамматик кагыйдәләрне сөйләмдә куллана алмаса,хаталар 6 дан артып китсә, "2"ле куела.

**Тестларны бәяләү**

"5"ле – 95 – 100 % үтәлсә;

"4"ле – 80 – 94 % биремнәргә җавап бирелсә;

"3"ле – 51 – 79 % биремнәр үтәлсә;

"2"ле – 51% тан да кимрәк дөрес җавап булса.

**Күчереп язуны бәяләү критерийлары**

1. Хаталары булмаган, төзәтүләрсез эшкә "5"ле билгесе куела
2. 1-2 хата һәм 1 төзәтелгән хата булса, "4"ле билгесе куела
3. 3 хата һәм 1 төзәтелгән хата булса, "3" ле билгесе куела

4. 4 хата һәм 1 – 2 төзәтелгән хата булса, “2”ле билгесе куела